РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 "а", Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «11» ноябрь 2019г. № 30

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам**:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге - Беренче Май бистәсендә теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Верхняя урамы 01 йорттан 33 йортка кадәр, Нижняя урамы 01 йорттан 16 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге - Беренче Май бистәсендә теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Средняя урамы 01 йорттан 12 йортка кадәр, Нижняя урамы 17 йорттан 35 йортка кадәр

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге - Беренче Май бистәсендә җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 22 ноябрь 2019 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 22 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Беренче Май бистәсе, Средняя ур. , 14 йорт, Беренче Май бистәсе мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены

карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә:

-423311,ТР, Азнакай районы, Беренче Май авылы, Средняя ур., 14й.

- сайлау хокукына ия булган Беренче Май пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Беренче Май пунктында халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2020 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Беренче май б., Югары (Верхняя) урамына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Беренче Май бистәсендә балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Беренче Май бистәсендә юлларны кардан чистарту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А й. (Башкарма комитет администрациясе бинасы);

-, Беренче Май бистәсе, Средняя ур., 14й. (Беренче Май бистәсе мәдәният йорты).

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Башлык: А.И.Закиров